СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

12 июль, 1997ел. ШИМБӘ

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | № 76 (8088) | Бәясе билгеләнгәнчә

# Район тормышы: вакыйгалар, хәбәрләр

## «Уңыш - 97» матбугат үзәге хәбәр итә

**Көчле яңгырлар терлек азыгы хәзерләүчеләрнең эшенә зур тоткарлык ясаса да, кыр эшләренең башкалары турында да кайгыртмый булмый. Синдряков исемендәге, «Киекле», «Якты Күл», Хафизов исемендәге хуҗалыкларда, МСО һәм «Агрохимсервис» ярдәмче хуҗалыгында үләне бер кат чабып алынган участокларны тамырдан тукландыруны чагыштырмача шактый мәйданнарда үткәрергә өлгерделәр. Башка хуҗалыкларда да бу эшне беренче мөмкинлек белән башкару өчен агрегатларны әзер тоту кирәк. Бер үк вакытта күпьеллык үләннәрне җәйге чәчүнең дә оптималь срокларын кулдан ычкындырмаска иде. Бу уңайдан аксымга бай культура - люцерна чәчүлекләрен киңәйтүгә зур игътибар бирү бурычы куела.**

**Чиста пар җирләрен эшкәртүне дә көндәлек игътибар үзәгендә тоту шарт. Игеннәр өлгереп килә торган басуларны урып - җыюга әзерләү, аерым алганда юл кырыйларын чүп үләннәрдән арындыру, басу читләрендәге азык культураларын чаптырып алу чарасына керешергә вакыт. Ә инде урак техникасын әзерләү турында әйткән дә юк.**

Район күләмендәгечә «Татарстан» КХАсында да сөт җитештерү быел арта төште. Июнь аенда хуҗалык сыер савучылары һәр сыердан былтыргы шул чор белән чагыштырганда 142 килограммга артыграк сөт саудылар. Тәҗрибәле савучылар Әкълимә Шиһапова, Резидә Фәсхиева, Тәнзилә Нуруллина, Фәүзия Хәрләмова, Гөлсем Сәлахова бүген дә малларыннан күбрәк сөт алу өчен тиешле ысулларны кулланып, барысын да эшләргә тырышалар.

Таналар группасында Әлфия Сәлахова әйбәт эшли. Батыр йөрәкле, җитез, өлгер куллы Әлфия быелгы сыер савучылар конкурсында катнашты. Җәй көннәрендә ул сыер саву кебек җаваплы эш белән чикләнеп калмыйча, быел гаиләсе белән хуҗалыкның бер алын чөгендер җирен дә эшкәртергә өлгерде.



**Рәсемдә: «Татарстан» КХАсы сыер савучысы Ә.Сәлахова.**

**Н.КВАШНИНА фотосы.**

## Хәбәрләр • Хәбәрләр • Хәбәрләр

### Яңа АВМ эшли

«40 лет Победы» хуҗалыгында АВМ җайланмасы әле беренче елын гына эшли. Шуңа карамастан, аның башлангычында торучылар биредә эшне төгәл һәм җиренә җиткереп башкаралар. Хәким Сәлихов җитәкчелегендәге бригада бүгенгә хуҗалык өчен 24 тонна печән оны әзерләде. Оста оператор - машинист Хәким биредә эшне төгәл һәм төпле башкара. «Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз» дигән мәкальне ул бик тирәнтен аңлый булса кирәк: һәркайда кулы ятып тора. Ул яхшы эретеп ябыштыручы да, АВМнан бушаган арада хуҗалыкның фермаларында слесарьлык итәргә дә өлгерә.

### Укучылар өчен... кибет

Әйе, китап кибетенең элекке «Канцтоварлар» бүлегендә ачылган яңа шәхси бүлек нәкъ менә укучылар мәнфәгатенә хезмәт итәчәк бит. Г.Н.Аркатова җитәкчесе булган «Мелита» бүлеге киштәләрендә - укучылар өчен өстәмә дәреслекләр, ярдәмлекләр, канцтоварлар, матур әдәбият үрнәкләре. Бүлек әле яңа гына эшли башласа да, аны бик тиз күреп алдылар. Хикмәтен эрактан эзлисе түгел: бүлектә товарлар төрледән - төрле булу өстенә, чагыштырмача арзан да.

## Ашаткан мал - артымлы

**Саннарның 1нче баганасы - район хуҗалыкларында быелның алты аенда мөгезле эре терлекләрдән, икенчесе - дуңгызлардан алынган уртача тәүлеклек артым (граммнарда).**

Малларның баш санын узган елгы дәрәҗәгә якынайту (күпчелек хуҗалыкларда мөгезле эре терлекләр былтыр ел уртасындагы кадәр инде, ә дуңгызлар район буенча да узган елгыдан 5 мең баштан күбрәккә артык), моңа беренче чиратта үрчем алуны яхшырту юлы белән ирешү нәтиҗәсе буларак, алты айда авыл хуҗалыгы җирләренең һәр йөз гектарына ит җитештерү 20,9 центнерга җитеп, узган елгыдан 4,7 центнерга артты. Синдряков исемендәге, «Родина» хуҗалыкларында, шикәр заводының ярдәмче хуҗалыгында бу күрсәткеч 26,6 - 29,1 центнер, Кузнецов исемендәге, Мичурин исемендәге, «Төрнәс» хуҗалыкларында да бу сан районның уртача күрсәткеченнән югарырак. Әмма «Киекле», «Үрнәк», «Заря», «Әлмәт», «Игенче» хуҗалыкларында, МСОның, нефтебазаның, «Агрохимсервис» ярдәмче хуҗалыкларында авыл хуҗалыгы җирләренең һәр йөз гектарына 10,8 - 12,6 центнер гына ит җитештерелде әле. Дөрес, аларның һәммәсендә бу күрсәткечнең узган елдагыдан ярыйсы ук күбрәк булуы игътибарга алырлык. Ә менә «40 лет Победы» хуҗалыгында бу күрсәткеч фәкать 7,9 центнер гына булды, узган елгыдан да 5,6 центнерга азрак. «Комбайн» хуҗалыгында һәр йөз гектарга иң аз - 4,7 центнер гына ит җитештерелде. Ул яктан былтыр эшләре күршеләренекеннән әллә ни кайтыш булмаган «Алга»да быел хәлне сизелерлек яхшырта алдылар бит әнә - авыл хуҗалыгы җирләренең һәр йөз гектарына ит җитештерүне өч ярым тапкырга арттырдылар биредә.

| | | |
|---|---|---|
| "Дуслык" | 668 | - |
| "Таң" | 647 | 345 |
| "Алга" | 621 | 159 |
| Шикәр заводы ярд.хуҗ. | 619 | 289 |
| "Рассвет" | 590 | 358 |
| "Якты Күл" | 559 | 326 |
| Синдряков исем. | 573 | 294 |
| "Кондырча" | 520 | - |
| "Родина" | 496 | 313 |
| "Агрохимсервис" ярд.хуҗ. | 499 | 231 |
| МСО ярд. хуҗ. | 488 | 283 |
| "Төрнәс" | 481 | 218 |
| "Әлмәт" | 476 | 245 |
| Мичурин исем. | 472 | 287 |
| "Татарстан" | 453 | 235 |
| "Заветы Ильича" | 443 | 348 |
| "Чирмешән" | 443 | - |
| "Киекле" | 437 | 85 |
| Хафизов исем. | 434 | 267 |
| Нефтебаза ярд. хуҗ. | 432 | 135 |
| Кузнецов исем. | 431 | 172 |
| М.Җәлил исем. | 424 | 286 |
| РСУ ярд. хуҗ. | 422 | 216 |
| "Игенче" | 406 | - |
| "Заря" | 401 | - |
| "Үрнәк" | 344 | 133 |
| Сөт - май комб. ярд. хуҗ. | 290 | 113 |
| "Комбайн" | 283 | 180 |
| "40 лет Победы" | 281 | 86 |
| **Район буенча** | **477** | **297** |

# АШЫГЫЧ ЯРДӘМ «ДОН»НАРЫ

Теләсә нинди әйберне таратуы җиңел, җыеп алуы гына авыр. «ДОН»нар белән дә шулай килеп чыкты: сиксәненче еллар азагында оешкан район җыелма отряды ике еллап элек «тар - мар» китерелеп, комбайннары хуҗалыкларга таратылган иде. Быел исә бу отрядны яңадан торгызу проблемасы күтәрелгәч, заманында хуҗалыкларга бер кул белән бирелгән техниканы инде кабаттан икенче кул белән тартып алу бер дә җиңел булмады. Өстәвенә шактый таушалган, алай гына да түгел, «таланган» булып чыкты алар. Шуңа да «Сельхозтехника» АҖнең комбайн депосына кайтарып куйгач та механизаторларга шактый җәфаланырга туры килде үзләре белән. Һәр комбайнның ышанычлы эшен тәэмин итү максатында рамаларына хәтле сүтелде алар. Шуннан соң күпме эретеп ябыштыру эшләре башкарырга туры килде. Ярый ла, Сергей Еремеев белән Владимир Захаров һәрчак янналарында булдылар. Теләсә нинди җөйне менә дигән иттереп ябыштыралар да куялар инде. Токарьлар Иван Трофимов белән Валерий Буланов та тулысынча дончылар карамагында эшләделәр бу көннәрдә.

Анысы чынлап торып эшлим дисәң, шартлар юк түгел мастерскойда. Электр җиһазлары буенча осталар, башка төрле ярдәмче эшчеләр һәрчак булышка килергә торалар, кран - балкалар һ.б. барысы да эш хәлендә. Запас частьләр юклыкка да әллә ни сылтап булмый: җәмгыять җитәкчелеге «ДОН»нарны якын көндә төзәтеп бетереп комплектлауны беренче планга куйгач иң беренче чиратта аларга кирәкле запас частьләр исемлеген булдырып, шуларны юнәтү мөмкинлеге таптылар. Иске запас частьләр дә реставрацияләнде.

Бүген җиде көнлек эш атнасы депода. Эш көне дә иртә башланып, соң гына тәмамлана. Комбайнчылар үзләренә дип эшләгәч, вак кына җитешсезлеккә дә күз йоммыйлар. Җыелма отряд дигәннән, биредә техника гына түгел, механизаторлар да җыелма. Боларын инде район авыл хуҗалыгы идарәсе кайгырткан. Комбайнчылар арасында без бу отряд составында бер генә ел эшләмәгән нефтьче Владислав Ендиряков, райподан Юрий Исаев, УТТдан Олег Юхмальчин, җылылык челтәреннән Фәйзулла Фәтхуллинны таныдык. Быел да алар җәен бер коллектив булып эшләргә ниятлиләр. Араларында яңалары да бар. Безгә аларның иң өметле, тырышларын күрсәттеләр. МППдан Илнур Фәхретдинов, УТТдан Александр Кузьмин, 127 нче ПМКдан Анатолий Кадяшев алар. Әлеге егетләрне ремонт вакытында ук сынарга өлгергән комбайн депосы мөдире Минислам Мөхетдинов әйтүенчә, үҗәт, җитез егетләр икән болары да.

Комбайнчыларның ярдәмчеләре дә бар. Алар да махсус сайлап алынган егетләр. Хәер, «ДОН» кадәр «ДОН»нарда хезмәт күнекмәсе булмаган, ялкау, пошмас кешеләрнең эшли алмавы бу эш белән азмы - күпме дәрәҗәдә таныш булган һәр кешегә мәгълүм инде.

Бүген депода кызу эш кайный: зур капкалар киң итеп ачылган. Яхшы итеп төзәтелеп әнә күзеннән үткәрелгән «ДОН»нарның бер ишеләре махсус мәйданчыкка чыгарып тезелгән. Механизаторлар үзләре исә ургычларны ремонтлау белән мәшгульләр. Икенче берәүләр исә депода соңгы хәзерлек чараларын күрәләр. Ремонт вакытында ук үзара танышып, дуслашып беткән комбайнчылар бер - берсенә булышалар, киңәшләр бирешәләр.

- Уракта сынатмаска исәп,- диләр егетләр.

Билгеле инде, 12 «ДОН»лы җыелма отряд - зур көч. Кайда эш акрынрак, катлаулырак барачак, заявка нигезендә шунда эшләячәкләр, гомумән, ашыгыч рәвештә ярдәм ролен үтәячәкләр «ДОН»нар.

**Р.ГИНЯЕВА.**

## Белми калмагыз!

***Бүген, шимбә көнне шәһәр стадионында сәгать 10да «Уяв» чуваш фольклор бәйрәме үткәрелә.***

**Кичен, 17 сәгатьтә - район мәдәният йортында игелек концерты. (Билет бәясе 5 мең сум).**

# СӨТНЕҢ СЫЙФАТЛЫСЫ - АКЧАЛЫ

## Район хуҗалыклары быелның беренче яртысында дәүләткә саткан сөтнең сыйфат күрсәткечләре

| Хуҗалыклар исемнәре | Хисаплау авырлыгы (центнерларда) | Майлылык (процентларда) | Хисаплаганда өстәп яки киметеп язылган | I сортлы сөт (процентларда) | I сорт белән суытып язылган сөт (процентларда) | I сорттан түбән һәм суытмыйча сатылган сөттән югалту (млн. сумнарда) |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «Киекле» | 4930 | 3,71 | + 147 | 73 | 41 | - 32 |
| Мичурин исем. | 8835 | 3,69 | + 208 | 87 | 56 | - 35 |
| Хафизов исем. | 9163 | 3,73 | + 330 | 93 | 58 | - 47 |
| М.Җәлил исем. | 2600 | 3,61 | + 5 | 89 | 48 | - 15 |
| «Родина» | 3578 | 3,58 | - 20 | 98 | 60 | - 35 |
| «Игенче» | 4015 | 3,64 | + 48 | 92 | 50 | - 20 |
| «Заветы Ильича» | 4522 | 3,64 | + 51 | 84 | 46 | - 21 |
| «Алга» | 4232 | 3,51 | - 111 | 86 | 40 | - 51 |
| «Комбайн» | 3404 | 3,73 | + 119 | 84 | 50 | - 12 |
| «Әлмәт» | 4561 | 3,50 | - 131 | 73 | 51 | - 53 |
| «Татарстан» | 4309 | 3,87 | + 306 | 99 | 98 | + 32 |
| «40 лет Победы» | 2748 | 3,62 | + 18 | 87 | 98 | - 12 |
| «Таң» | 2022 | 3,73 | + 73 | 84 | 44 | - 7 |
| «Үрнәк» | 4186 | 3,77 | + 193 | 88 | 51 | - 4 |
| «Кондырча» | 5056 | 3,81 | + 275 | 97 | 36 | + 3 |
| Кузнецов исем. | 7658 | 3,63 | + 66 | 95 | 39 | - 39 |
| «Заря» | 2925 | 3,60 | + 1 | 98 | 27 | - 11 |
| «Чирмешән» | 6813 | 3,70 | + 183 | 98 | 75 | + 3 |
| Синдряков исем. | 4548 | 3,54 | - 77 | 99 | 48 | - 36 |
| «Рассвет» | 3056 | 3,86 | + 204 | 92 | 17 | + 10 |
| «Якты Күл» | 4013 | 3,80 | + 208 | 97 | 34 | + 3 |
| «Норлатнефтепродукт» АҖ ярд. хуҗ. | 2296 | 3,61 | + 6 | 85 | 21 | - 20 |
| «Шикәр заводы» АҖ ярд. хуҗ. | 4535 | 3,60 | - | 83 | 53 | - 29 |
| «МСО» ярд. хуҗ. | 3234 | 3,48 | - 115 | 75 | 53 | - 41,4 |
| «Сөт - май комбинаты» АҖ ярд. хуҗ. | 2325 | 3,73 | + 83 | 97 | 56 | - 11 |
| «Төрнәс» | 6288 | 3,68 | + 133 | 77 | 46 | - 38 |
| РСУ ярд. хуҗ. | 3205 | 3,86 | + 204 | 89 | 59 | - |
| «Агрохимсервис» ярд. хуҗ. | 3887 | 3,64 | + 42 | 80 | 62 | - 18 |
| **Район буенча** | 128394 | 3,67 | + 2483 | 89 | 51 | - 536 |

Район хуҗалыклары быел алты айда хисаплау исәбендә сөт хәзерләүне узган елның шул чорындагыдан 26.601 центнерга арттырдылар. Моңа продукциянең майлылыгын 0,9 процентка күтәрүгә ирешү дә зур булышлык итте. Шуның нәтиҗәсендә генә дә алты айда 2483 центнер сөт өстәлде һәм бу 272,8 миллион сум акча өстәп язылды дигән сүз. Бу яктан быел хуҗалыкларның абсолют күпчелеге сөтнең сыйфатын яхшыртуга иреште. Әмма берничә хуҗалыкта элеккечә үк бу мәсьәләгә тиешле игътибар юклыгы үзен сиздерә. (Андыйлар рәтенә кемнәр керүе мәгълүматлардан ачык күренә).

Югалтулар әле бер моның белән генә дә бетми. Район буенча быелның беренче яртысында I сортлы сөт сату узган елның шул чорындагыдан 5 процентка артса да, дүрт хуҗалыктан сөтнең чиреге диярлек I сорттан түбәнрәк кабул ителде. Ә инде сөтне суытып сату мәсьәләсенә килгәндә хәл бигрәк тә аяныч. 13 хуҗалыктан китерелгән сөтнең яртысына якыны дәүләт стандарты таләпләренә җитәрлек иттереп суытылмаган иде. Нәтиҗәдә район буенча сөтнең куелыгы базис майлылыгыннан югарырак булган өчен өстәп язганга караганда ике тапкырга диярлек күбрәк акча сөтне суытып тапшырмаган өчен кулдан ычкынды. Бу кайбер хуҗалыклар мисалында аеруча ачык күренә. Әйтик, «Татарстан»лылар сауган сөтләре куерак булган өчен 306 центнер сөт, саткан сөтләренең 98 проценты I сортлы һәм суытылган булганга 32 миллион сум акча өстәп язылуга ирешкән һәм сөтләренең килограммы 1188 сумнан киткән бер вакытта, МСОның ярдәмче хуҗалыгында берьяклап 115 центнер продукция югалтсалар, икенчедән 41 миллион өстәмә акчадан колак кактылар, чөнки алардан сөтнең сатып алыну бәясе һәр килограммга 128 сум түбәнрәк чыкты.

Хәер, мондый мисалларны күпләп китерергә мөмкин әле, чөнки дәүләткә сатыла торган сөтнең сыйфат күрсәткечләренә карата һаман да җитди карамаучы хуҗалык җитәкчеләре һәм белгечләр бар, югыйсә, алда телгә алынган хуҗалыктан, шулай ук «Заря», «Алга», «Киекле», Мичурин исемендәге хуҗалыклардан, нефтебазаның ярдәмче хуҗалыгыннан сөтнең майлылыгын да, авырлыгын да үлчәп мәшәкатьләнмичә озатуларын ничек аңлатасың ди?

Ә бит хәзер продукция һәм чималның сыйфатына халыкара таләпләргә җавап бирердәй яңа, күтәренкерәк стандартлар әзерләнә һәм игенчелек культураларына карата алар быел гамәлгә кертелде дә инде. Әгәр продукциянең сыйфатына караш алга таба да бүгенгечә калса, моның нәтиҗәләре (чыгымнары дип аңла) тагын да аянычрак булырга мөмкин.

**А.БЕЛЯКОВА,**
**авыл хуҗалыгы продуктлары хәзерләү һәм сыйфат буенча дәүләт инспекторы.**

# ЯШЬКӘ ГЕНӘ ЯШЬ УЛ

Сабанчыларның район конкурсында катнашкан утыз механизатор арасында иң яше иде ул. Әмма бәйгедә «1нче Май» хуҗалыгы механизаторлары данын яклауның 22 яшьлек Юрийга ышанып тапшырылуы очраклы түгел икән, яшь кенә булса да гомерлек тракторчылар белән бил алышырга чыгарга тулы хокукы бар икән егетнең. Шулай булмыйча соң, әтисе Вячеслав Иванович янында башта буталып, аннан инде тракторның рычагларын да тарткалап карап йөри башлаганы, кем әйтмешли, тәпи басканнан ук дисәң дә артык түгелдер. Шуңа да дүртенчене бетерүгә әтисенең тракторын мөстәкыйль рәвештә ду китерә башлый инде Юра. Һәм аның соңрак бу хезмәтне үзенә төп һөнәр итеп сайлавына аптыраучы булмый. Хәрби хезмәткә дә Юрий инде яшьтәшләренә караганда ярыйсы ук хезмәт стажлы, эш рәтен белә торган, беләгенә көч җыйган егет булып китә. Солдат хезмәтен бу заман егетләренең бик күбесенең өлешенә чыккан кайнар ноктада - Чечняда узарга туры килә аңа. Язмышына язылган бу чор турында сүзе кыска Юрийның: »Барысын да күрергә туры килде инде...» Шуңа да туган авылына кайткач куллары яңадан тыныч корал - трактор рычагларына тотынырга үзләре үк атлыгып торалар да. Әтисе, үзе тәгәрмәчлесенә күчеп утырып, ДТ-75ен аңа тапшыра һәм шуннан бирле Юра «1нче Май» хуҗалыгында иң уңган, иң булдыклы механизаторлар исәбендә. Әле менә язгы чәчү йомгаклары буенча иң алдынгы булып чыкты. Шуңа күрә сабанчылар ярышына нәкъ менә аны җибәргәннәр дә инде. Мондый бәйгедә беренче генә елын катнашкан Юрий быел призлы урынга ук чыга алмады әле. Әмма туган җирне яратучы, шунда тырышып хезмәт итүдән үзенә тормыш яме табучы егетнең алга таба мондый сынауларда тагын да кыюрак булачагына шикләнмәскә мөмкин. Ә хезмәт сөючәнлек, кечкенәдән эшкә өйрәнеп, кул арасына кереп үсү Тихоновларның нәселенә хас сыйфат. Әнә Юрийның энекәше Андрей әле уналтысын гына тутырган булса да чылбырлы тракторны иярли, хуҗалык механиазаторлары ярышында абыйсының үкчәсенә басып килә. Армиядән соң терлекчелектә эшли башлаган тагын бер уллары Дмитрий да хезмәт сөючән. Шуңа да Вячеслав Иванович белән Ирина Александровнаның берсеннән берсе уңган уллары белән горурланырлыклары бар.



**Рәсемдә: «Норлат» агрофирмасының «1нче Май» хуҗалыгы механизаторы Юрий Тихонов.**
**Н.КВАШНИНА фотосы.**



Тамара Андреева белән Ольга Семенова РСУның Козлов исемендәге ярдәмче хуҗалыгында иң тәҗрибәле терлекчеләрдән саналалар - хезмәт стажлары берничә дистә елга җыела аларның. Эш дигәндә бик тырышлар, үҗәтләр. Әле менә җәйләүгә күчкәч тә сөтне мөмкин кадәр арттырабыз дип сүз куешканнар иде, вәгъдәләренә тугъры калдылар - бүген алар группасындагы маллар көнгә уртача 15әр килогррамм сөт бирә.

**Рәсемдә: савучылар Т.Андррева һәм О.Семенова.**
**Н.АЗИЗОВ фотосы.**

● *Бер хуҗалык хәбәрләре*

## Кырда эш бетеп тормый


Хафизов исемендәге хуҗалык механизаторлары чәчүлекләрне карауның барлык агротехник таләпләрен төгәл үтәргә тырышып эшлиләр. Аерым алганда, шикәр чөгендеренең рәт араларын эшкәртүдә Мансур Насыйбуллин белән Якуб Кәримов, кукурузны өстәмә тукландыруда Миншакир Кәримов вакытның кадерен белеп кенә эшләделәр. Чәчүлекләрне төрле корткычларга, үсемлек авыруларына каршы гербицидлар белән эшкәртү кебек мөһим агрочара да ике мең ярым гектар чамасы мәйданда җиренә җиткереп уздырылды.

## Сөт муллыгы хакына

Терлекчеләр белән беррәттән башка һөнәр ияләре дә хезмәтләрен кызганмыйлар. Механизатор Мөнир Гыйләҗев, мәсәлән, малларга яшел масса чаптыруда иртәдән кичкә кадәр тырышлык куйса, вакланган массаны җәйге лагерьдагы малларга ташуда Вәзир Сафиуллин иренә торганнардан түгел. Ул кайтарган туклыклы яшел азык көне - сәгате белән маллар алдына таратыла.

**Т.ДЕРБЫШЕВ,**
**хәбәрче.**
**июль,**
**1997 ел**

## Ирек Камалов



# Сары чәчәкләрне өзмәгез...

### повестьтан өзек

Аккан сулар юл тапкан шикелле, тормышта үз юлыннан ага торды. Көннәр бер - бер артлы уза торды. Вакыйгалар, берсен - берсе алыштырырга да өлгерә алмыйча, үзгәреп, яңарып кына торды.

Азат та санаторийдан кайтып, үзендә өр - яңа көч - куәт сизгәндәй эшкә башлады. Тормыш дигәннәре әллә ничек кенә шунда?!

Бертөрле уй - фикер белән яңабаштан яшәгәндәй итсәң дә, телисеңме, теләмисеңме, узган гомерләрне барлыйсы килә. Ә үткәннәр татлы да, газаплы да икән, югыйсә. Шулай булмаса, ул кичерешләр белән яшәгән минутлар Азатның тәне буйлап, сихәтле җылы агым булып узар идеме. Әнә шул мәлдә генә ул дөньяның иркенлегеннән тоя, кабат яшәреп киткәндәй була. Авыр минутларны җиңә алырлык, сагышлы уйлар эчендә дә йөзә Азат. Ләкин күңелсезлекләр, фаҗигалар эссез генә узмый икән, шул вакыт тамак төбенә ниндидер бер төер утыра. Ә төер җиңел генә төшеп китәргә җыенмый, күз алмасыннан ачы яшь сыгылып чыга һәм ирексездән түбән тәгәри. Бары тик йөрәк кенә бирешмәскә боерык биргәндәй, сулкылдап тибүен белә.

Әллә ничек шунда. Азат соңгы елларда олыгаеп, картаеп китте, элек атлап йөрисе урынга, чабып кына йөрергә күнеккән аяклары, адымнары салмакланды. Тормыш тезгенне барыбер тартты бугай, ул күп вакыт үз эченә бикләнеп яши торган булды. Тик хисләрне тоткынлыкта яткырырга ирек бирмиләр. Өеңә кайтып керүгә елмаеп кайгыртучан анасы каршы йөгереп чыга. Балалары, оныклары бер - бер артлы сораулар белән күмә, киңәшләр сорыйлар. Ике кечкенә оныгы, өстәл янына килүгә, бабаларының итәгенә менеп утыралар да балалар бакчасында ни күргәннәрен бытылдыйлар. Тагы өстәп телевизордан күргән «Ну погоди!» дигән мультфильмда ничек итеп куянның бүредән тоттырмавын аңлатырга, күрсәтергә тырышып, сабыйларча шырык - шырык кычкырып көләләр. Бабаларының кушылып көлүенә шатланалар да, әйтеп куялар:

- Бабай, син «Әлли - бәлли - бәү»дәге бабайга охшагансың икән, чәчләрең дә агарган. Әйдәле, син ат бул, без сиңа атланып өйне әйләник,- диләр.

Әйе, Азатка шул балалар белән бер шаярып алу үзе ял, үзе шатлык - куаныч, чөнки дөнья мәшәкатьләре шул мизгелдә әллә кай җирләргә олагып, югалып торгандай була. Дәү әниләренең бабаларына ирек бирмәгән сабыйларны тиргәп алуы да алар өчен мөһим түгел. Алар янә бабаларының муеныннан кысып - кысып кочакларга, битләреннән «пәп» итәргә керешәләр. Өстәвенә олы улының малае Рамилнең, мәктәптән кайтышлый көндәлегендәге «5»ле билгеләрен, дәфтәрләрен бабасына шатлана - шатлана күрсәтүе булган хәсрәтләрен, кайгы - кичерешләрен тарата.

Кайгы - хәсрәт дигәннән, адәм баласына бер хәсрәтсез торырга язмаган икән.. Шулай тормышны матур гына көйләп йөргәндә Азат Фәридәсен төшендә күрде. (Соңгы вакытларда Фәридә төштә чуалмый диярлек иде).

Ягымлы, җылы яз көне, имеш. Бар җиһан ап - ак чәчәктә. Ул да түгел, ап - ак чәчәкле алма, чия агачлары арасыннан ике кулын сузып Фәридә Азатка таба килә, имеш. Җәйге җиңел, нәфис кенә ак ситса күлмәк кигән, ә ак җирлеге өстенә зәңгәр кыңгыраулар төшкән, имеш. Башына да шул төскә тартым ефәк яулык япкан.

- «Азат, акыллым, мин әнине дә, сине дә бик сагынып кайттым. Зинһар каршы килә күрмә, әнине бүген үк үзем белән алып китәм. Әнкәйнең йорты ике айдан өлгереп бетәчәк. Мин аны бөтенләйгә алып китәргә, дип кайттым. Берүземә бигрәк күңелсез бит. Әнине шундый сагындым...»

Уянып киткәндә, Азат шабыр суга баткан, хәтта телен тибрәндерерлек тә хәле юк. Әйтерсең, теле аңкавына ябышкан. Ул бу мәхшәрне өн дип тә, төш дип тә атарга белмәде. Фәридә әле генә томан эченә кереп югалгандай булды. Азат та яшен тизлеге белән урыныннан сикереп торды, әле генә Фәридә басып торган урынга, тәрәзә аша бакчага карады. Урам утларыннан саран гына яктыртылган бакчада инде беркем дә күренмәде. Ул әллә нигә юрарга да теләмичә генә, аяк очларына басып, әнисе ята торган бүлмәгә атлады. Ятагында әнисенең тигез сулыш алып, матур гына йоклап ятуына сөенә - сөенә, «и, ходаем, бу төш кенә икән бит», дип, кире чыгып үз урынына ятты. Бу хәлдән соң тынычлана алмыйча, йокылы - уяулы ятып таңны аттырды. Ләкин Фәридәсенең елмаюлы нурлы йөзе һаман күз алдыннан китмәде. Аның башына әллә нинди төпсез уйлар килеп йөдәтте. Әнисе дә Азатны ташлап китә калса? Авыр чакларда чал башын кемнәр җилкәсенә салыр да, кемнәрдән назлау эзләр, яклау сорар?

Ә бит коточкыч сугыш елларында аны әнисе ничек какмый - сукмый үстерде. Азатның абруйлы дәрәҗәгә ирешүендә әнисенең өлеше бернинди үлчәүләргә салып та үлчәп булмаслык зур, чиксез иде. Шуның өчен дөньялыкта анасын бәхилләтеп бетерерлек, рәнҗетмәслек нәрсәләр эзләп азапланды. Әгәр кирәк икән, кояшын, аен бирергә әзер кебек иде ул. Ләкин аның өчен җанын да бирәчәгенә иманы камил иде.

Ә бит бу фани дөньяда аналарын язмыш кочагына ташлап яшәүче аның күршесендә генә яшәп ята. Азат бу хәлләрне күреп эчтән генә бик сыкрый, андыйларга хәлдән килгәнчә ярдәм итәргә тырыша.

Азат тагын башын түбән иеп авыр хисләргә бирелде...

### Уены - чыны бергә

## Күрсәт кулыңны-әйтәбез кемлегеңне

Әгәр синең тырнакларың укучы балаларныкы төсле кыска итеп кискән һәм чиста икән, димәк, син бик җитди кеше. Бәлки артыгы белән җитдидер? Кеше фикере белән санашасың. Ә үз фикерең бармы? Сиңа бераз үз-үзеңә ышаныч һәм тормыш шатлыклары җитми.

Инде тырнагыңда иске маникюр эзләре, кырылган лак күренсә, тырнак асларың пычрак булса, син - даими түгел. Кайчак син элегантлыкка омтыласың, икенче бер вакыттулысы белән битарафлыкка чумасың. Әйт әле, соңгы тапкыр чәчеңне кайчан юдың?

***

Бармагыңда шариклы ручка эзләре- син тирә юньдәге вак-төяккә игътибар бирмисең, синең мөһим эшләрең күп. Ихтимал!Шулай да исегезгә төшерәбез: ручка эзен салицил спирты белән сөртеп яки юганда пемза белән бетереп була.

***

Бармагыңда әбиеңнең тар гына балдагы-син бераз сентиментальрәк, әмма үзеңне андый түгел дип саныйсың.

***

Зур, ялтыравыклы ташлы йөзек - син әйләнә-тирәдәгеләрнең игътибарын җәлеп итәргә телисең, әмма-берничек!

***

Күзгә бәрелеп торган «кызыклы» йөзексинең артистлыкка тартымың бар. Зәвыкны үстерергә тырышасың.

***

Ике яки аннан артык йөзек - синең яшәү һәм киенү рәвешең бераз гаҗәбрәк тоелмыймы?

***

Үзеңне танып,хәтерең калмадымы?

**«Женщина» газетасыннан.**

## Котлыйбыз!



Чулпан авылында яшәүче кадерле әниебез **Кәүсәрия Гаяз кызы Шәйхуллинаны** 50 яше белән кайнар котлыйбыз.

Әнкәй, җиңел булмагандыр
Үтү гомер юлларын.
Сиңа озын гомер тели
Кызларың һәм улларың.

**Иң изге теләкләр белән тормыш иптәше, балалары, килене, кияве, оныклары.**

## Сатабыз




**Чулпанда йорт яны корылмалары белән йорт.** Бәхтияровларга мөрәҗәгать итәргә.

***

**Чистарту корылмалары районында базы белән капиталь гараж.** Тельман ур., 6 - 11 адресы буенча мөрәҗәгать итәргә. Тел.: 4 - 22 - 19.

***

**40 лет Октября урамында 45 нче йорт сатыла, әйбәт хәлдә.** Куйбышев ур., 43 - 8 адресына мөрәҗәгать итәргә.

***

**Азык комбинаты районында төзелеп бетмәгән гараж, кыйммәт түгел.** Тел.: 2 - 15 - 08.

***

**1990 елгы ВАЗ - 2105**. Тел.: 5.- 12 - 77.

***

**ВАЗ - 2106, кыйммәт түгел**. Тел.: 5 - 12 - 77.

***

**«ИЖ - Планета», 3 х 4 метрлы чанадагы гараж, кыйммәт түгел.** Адрес: Козлов ур., 3 - 11.

***

**Шәһәр үзәгендә бер бүлмәле фатир.** Тел.: 2 - 27 -43 5 - 18 - 55.

***

**2 бүлмәле фатир**. Адрес: К.Маркс проспекты, 2 - 2.

***

**Линейная урамында капиталь гараж**.
Адрес: Садовая ур., 29 - 81 (18 сәг.тән соң).

***

**Октябрь хуҗалыкара төзелеш оешмасы Каравыл Тавы заводыннан мең данәсен 660 мең сумнан кызыл кирпеч сата. Теләүчеләргә транспорт чыгымнары түләп - өйгә илтеп бирергә мөмкин.** Тел.: 2 - 12 - 61.

***

**СПТУ районында төзелеп бетмәгән агач йорт, гомуми мәйданы 62,5 кв.метр**. Адрес: Лермонтов ур., 11. Тел.: 2 - 25 - 99.

## Эшкә чакырабыз

***Н.Октябрь хуҗалыкара төзелеш оешмасына ашыгыч рәвештә*** **ташчылар, электр һәм газ белән эретеп ябыштыручылар, мастерлар, прораблар, балта осталары, электриклар, тимер - бетон конструкцияләрне формалаучылар** ***кирәк.***

***Өлешчә катнашу һәм 10 ел эчендә түләү шарты белән торак бирү гарантияләнә, шулай ук 5 ел эчендә килешү бәясендә түләү шарты белән төзелеп бетмәгән 2 фатирлы торак йортлар тәкъдим ителә.***

**Җәмәгать туклануы предприятиеләренең хуҗалык исәпле берләшмәсенә 4-5 разрядлы пешекчеләр, җәмәгать туклануы технологы, электрик кирәк.**

***

**«Мелиорация Октябрь ПМКсы» АҖ (127 нче ПМК) 4-5 разрядлы газ һәм электр белән эретеп ябыштыручыларны даими эшкә чакыра. Хезмәткә түләү-эш башыннан.**

***

## Төрлесеннән

**2нче мәктәпне тәмамлау турында Кудряшов Павел Владимирович исеменә бирелгән А 1292281 номерлы аттестатны, югалу сәбәпле, гамәлдән чыккан дип исәпләргә.**

***

**«Дружба» бакчачылык ширкәтендә участоклары булган кешеләрнең дача участокларына дәүләт акты алу өчен түбәндәге адрес буенча килүләрен сорыйбыз:** Гыйматдинов ур., 79, «Надежда» дәүләт предприятиесе конторасы бинасы.


БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**

МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА**

**Учредительләр: Октябрь район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.**

**"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.**

**Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Норлат шәһәре, Карл Маркс урамы,19.**

**Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, җаваплы сәркәтип - 2-18-67, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия,реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.**

*Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.*

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2306 данә.